| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

№56 Алабуга шәһәре «30» март 2026 ел

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип тану турында.

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе Президентының кайбер актларын үзгәртү һәм үз көчләрен югалтуын тану турында» 2025 елның 31 декабрендәге 1009 номерлы Указы нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы

КАБУЛ ИТТЕ:

1. Алабуга муниципаль районы Советының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

- «Алабуга муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләрен һәм аларның гаилә әгъзаларын Алабуга муниципаль районы рәсми сайтында муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр урнаштыру тәртибе хакында Нигезләмәне раслау турында һәм әлеге белешмәләрне бастырып чыгару өчен бөтенроссия массакүләм мәгълүмат чараларына бирү хакында» 2017 елның 28 августындагы 198 номерлы карары;

- «Санлы финанс активлары һәм санлы хокуклар турында белешмәләр бирү турында һәм Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 10 июнендәге 77 номерлы карары;

- «Алабуга муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләрен һәм аларның гаилә әгъзаларын Алабуга муниципаль районы рәсми сайтында муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр урнаштыру тәртибе хакында Нигезләмәне раслау турында һәм әлеге белешмәләрне бастырып чыгару өчен бөтенроссия массакүләм мәгълүмат чараларына бирү хакында» 2022 елның 12 августында 186 номерлы карары.

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль корылыш һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Рәис урынбасары А.В. Косов